# *Чистай шәһәре 2 нче номерлы гимназиянең этнографик музее программасы*

Төзүче: татар теле һәм
әдәбияты укытучысы
Гыйльманова Сәкинә
Минеһади кызы.

## Аңлатма язуы

Һәр халык үзенең традицияләре, гореф-гадәтләре белән бай.”Үткәнен белмәгән халыкның киләчшге юк”,- диләр. Дөрес сүзләр. Әуңа күрә хәзер көн-күрешебезгә төрле йола-бәйрәмнәр күбрәк үтеп керә; халык хәтере булып, музейлар барлыкка килә.

Гимназиябездә 2000 нче елда ачылган музей тәрбия эшендә зур әһәмияткә ия. Анда тупланган экспонатлар, материаллар ярдәмендә укучыларны актив эшчәнлеккә юнәлтеп, аларның күңелендә мәрхәмәтлелек, шәфкатьлелек хисе уятырлык күп төрле чаралар үткәрергә була.

Үз халкыбызның чын тарихын өйрәнү- бу безнең бурычыбыз, чөнки ул зиһенне баета, дөньяга карашны киңәйтә, туган җиргә мәхәббәтне арттыра.

**Максат:** Татар халкының, шәхәребезнең, гимназиянең тарихын өйрәнүгә кызыксыну уяту, укучыларда иҗади сәләтләрен үстерү, әхлакый зәвык тәрбияләү.

**Бурычлар.**

1.Туган як турында мәгълүмат бирергә.

2.Укучыларның шәхси ресурсларын киңәйтергә һәм иҗади эшчәнлеген үстерергә.

3.Гимназистларны эзләнү-тикшеренү эшчәнлеге нигезендә тупланган материалларны, белемнәрне дәрестә куллана белергә өйрәтергә.

4.Укучыларда гражданлык сыйфатларын һәм патриотик хис тәрбияләргә.

5.Аралаша белү сәләтенә өйрәтергә һәм бәйләнешле сөйләм телен үстерергә.

**Эчтәлек.**

1.Халкымның үткәнү турында сөйли торган экспонатлар 10 сәг.
туплау, аларның тарихын өйрәнү.

2.Туган шәһәребезнең үткәне һәм бүгенгесе турында белем-
нәрен каммиләштерү. 10 сәг.

3.Шәхәребезнең күренекле турында мәгълүматлы булу. 2сәг .

4.Гимназия тарихы белән танышу һәм мәгълүматны баету. 6сәг.

5.Ветеран укытучылар турында альбомнар төзү. 6сәг.

6.Милли йолалар һәм гореф-гадәтләр. 10сәг.

9.Халык авыз иҗаты(бәетләр,такмаклар,әкиятләр) туплау. 10сәг.

10.Шәҗәрәләр төзү, бәйгесе оештыру. 4сәг.

11.Башка музейларга эскурсияләр оештыру. 6сәг.

| Эш төрләре | Сәгать саны | Үткәрү вакыты |
|---|---|---|
| 1. Оештыру өлеше. Группа туплау.<br><br>2. Кереш дәрес План белән таныштыру.<br><br>3. Музейдагы экспонатларны барлау. Экскурсоводлар белән эшләү.<br><br>4. Туган шәһәребезгә карата материалларны өйрәнү һәм баету. Экскурсоводларны эзерләү.<br><br>5. Шәһәребез тарихына карата материал туплау.<br><br>6. Олы буын кешеләре белән очрашу, әңгәмәләр үткәрү, экспонатлар җыю.<br><br>7. Җыелган материалларны туплау, тәртипкә китерү.<br><br>8. Г.Исхакый музеена экскурсия.<br><br>9.1нче сыйныф укучыларын музей белән таныштыру.<br><br>10. Тукай урамына чыгу. Олы кешеләрдән халык авыз иҗаты үрнәкләрен туплау.<br><br>11. Җыелган материалларны барлау.<br><br>12. Туган як бәетләре язып алу.<br><br>13. Туплаган бәетләрне уку, фикер алышу<br><br>14. Халык авыз иҗаты туплауны дәвам итү.<br><br>15. 2нче сыйныф укучыларын музейга чакыру.<br><br>16. Гимназия тарихы. Материаллар белән танышу.<br><br>17.3,4 сыйныф укучыларын музей белән таныштыру<br><br>18.Каникулда җыйган материалны эшкәртү.<br><br>19.5А сыйныф укучыларын музей белән таныштыру.<br><br>20.Шәһәрнең үзәк музеена экскурсия. | | |

| | | |
|---|---|---|
| 21.6 нчы А сыйныф укучыларын музей белән таныштыру.<br><br>22.Гимназия тарихы. Альбомнар белән эшләү.<br><br>24.Ветеран укытучылар турында мәгълүмат туплау.<br><br>25.6 нчы Б сыйныф өчен экскурсия оештыру.<br><br>26.”Шәҗәрә-тәрбиянең асыл ташы” дигән бәйгегә әзерлек эше алып бару.<br><br>27.7 нче сыйныф өчен экскурсия оештыру.<br><br>28.Ветеран укытучылар турында альбом төзү.<br><br>29.8 нче А сыйныфы өчен экскурсия оештыру.<br><br>30.Милли йолалар турында.<br><br>31.I яртыеллыкта тупланган материаллар турына һәм киләчәккә планнар турында фикерләшү.<br><br>32.Җирле шагыйрьләр белән очрашуга үзәк китапханәгә бару.<br><br>33.9 нче А сыйныфы өчен экскурсия оештыру.<br><br>34.Казан турындагы альбомнар белән эшләү.<br><br>35.9 нче Б сыйныфын музей белән таныштыру.<br><br>36.Р.Фәхретдин китабы белән таныштыру.<br><br>37.Башка мәктәп музейларына чыгу.<br><br>38.”Шәҗәрә-тәрбиянең асыл ташы”- бәйге.<br><br>39.10 сыйныфы өчен экскурсия.<br><br>40.Туган шәһәремнең күренекле шәхесләре.<br><br>41.Татар балалар бакчасы музейда кунакта. | | |

| | | |
|---|---|---|
| 42.Шәһәребез мәчетләрен тарихы.<br><br>43.Якташ язучы-Кояш Тимбикова турында мәгъ-лүмат туплау.<br><br>44.Пастернак музеена бару.<br><br>45.Кояш Тимбикова турында альбом төзү.<br><br>46.Иншалар конкурсы “Туган шәһәремнең үткәне һәм киләчеге”.<br><br>47.Халык авыз иҗатын туплауны дәвам итү.<br><br>48.Тупланган материалларны эшкәртү.<br><br>49.Нәүрүз бәйрәменең тарихы.<br><br>50.Нәүрүз бәйрәме оештыру.<br><br>51.Г.Исхакыйның туганы Әминә апа белән очрашу.<br><br>52.Г.Исхакый турындагы материаллар белән эшләү.<br><br>53.Чистай шәһәренең сугыш ветераннары турында мәгълүмат җыю.<br><br>56.Татар урамнарына чыгу, өлкән буын кешеләреннән сугыш хәтирәләре язып алу.<br><br>58.Музейда тупланган материалларны тәртипкә китерү.<br><br>60.Еллык эшкә анализ, киләчәккә планнар. | | |